**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2024 елның 20 ноябрендәге 4730 номерлы карары**

# Казан шәһәре Башкарма комитетының 2012 елның 24 маендагы 3274 номерлы «Казан шәһәре бюджетыннан ассигнованиеләр ала торган муниципаль учреждениеләрнең түләүле хезмәтләре турында»гы карарына үзгәреш кертү хакында

Казан шәһәре муниципаль учреждениеләре тарафыннан түләүле хезмәтләр күрсәтү эшен оештыру һәм тәртипкә салу максатыннан **карар бирәм**:

1. Казан шәһәре Башкарма комитетының 2012 елның 24 маендагы 3274 номерлы «Казан шәһәре бюджетыннан ассигнованиеләр ала торган муниципаль учреждениеләрнең түләүле хезмәтләре турында»гы карары (аңа Казан шәһәре Башкарма комитетының 2015 елның 8 июнендәге 2304 номерлы, 2019 елның 15 апрелендәге 1311 номерлы, 2022 елның 28 июнендәге 2041 номерлы, 2024 елның 1 мартындагы 720 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) кушымтасына, түбәндәге эчтәлектәге VII бүлек белән тулыландырып, үзгәреш кертергә:

«VII. Казан шәһәре Башкарма комитетының Мәгълүмат технологияләре һәм элемтә идарәсе карамагындагы муниципаль учреждение

7.1. Мәгълүмат технологияләре өлкәсендәге хезмәтләр:

7.1.1. мәгълүмат системаларын эшләү, модернизацияләү һәм проектлау;

7.1.2. мәгълүматлар базаларын эшләү, җайлаштыру, модификацияләү, мәгълүматлар базаларын урнаштыру, тест ярдәмендә тикшерү һәм аларга хезмәт күрсәтү;

7.1.3. мәгълүматларны эзләү, аларны сайлап алу һәм сорату буенча сортларга аеру, сайлап алынган мәгълүматларны, шул исәптән турыдан-туры файдалану мөмкинлеге режимында, кулланучыларга җиткерү;

7.1.4. программа белән тәэмин итүне һәм гамәли программаларны эшләү;

7.1.5. программа белән тәэмин итүне тест ярдәмендә тикшерү, программа белән тәэмин итүне интеграцияләү;

7.1.6. мәгълүмат ресурслары булдыру.

7.2. Проект белән идарә итү һәм сакчыл җитештерү өлкәсендәге хезмәтләр:

7.2.1. сакчыл технологияләр һәм цифрлы тәкъдимнәр концепциясен кулланып, оешманың бизнес-процессларын модельләштерү һәм оптимальләштерү;

7.2.2. проект эшен автоматлаштыру.

7.3. Бизнес-процессларны оптимальләштерү һәм автоматлаштыру буенча хезмәтләр:

7.3.1. мәгълүмат системалары аудиты, тикшерү, консалтинг;

7.3.2. мәгълүмат җыю, модельләштерү, фаразлау, анализлау;

7.3.3. бизнес-процессларны автоматлаштыру.

7.4. Мәгълүмат-аналитика эшчәнлеге өлкәсендәге хезмәтләр:

7.4.1. мәгълүматларны модельләштерү, фаразлау һәм анализлау;

7.4.2. ачык һәм яшерен чыганаклардан алына торган мәгълүматлар нигезендә фаразларны җыю, эшкәртү, гомумиләштерү, анализлау һәм төзү».

2. Әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карар «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) рәсми басылып чыкканнан соң гамәлгә керә дип билгеләргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары И.С.Шакировка йөкләргә.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**